**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

17 нче октябрь 2019 ел №126

**Җирле салымнар һәм җыемнарга недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү**

Россия Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Татарстан республикасынын «Региональ салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турында» 2017 нче елнын 19 июлендэге № 54-ТРЗ карары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль закон, «Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендэ һәм җирле салымнар һәм җыемнар буенча чынга ашмаслык бурычларны түләттерүне җайга салу максаты белән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Түбәндәге нигезләр буенча недоимканы, пеня һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсезлекне тануның өстәмә нигезләрен билгеләү:

1) гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны түләттерү өчен вакыт чыгу;

2) гамәлдәге җирле салымнар буенча бурычларны түләттерү өчен, өч елдан артык вакыт узган, гомуми суммада 100(йөз) сумнан артмаган бурычларны түләтү өчен дәгъвалы вакыт чыгу;

3) 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы "Башкарма производство турында" гы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма битләр һәм суд боерыклары буенча физик затлардан җирле салымнар буенча бурычларны мәҗбүри түләттерү мөмкинлеге булмау;

4) вафат булган физик затлар яисә федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә вафат булган затлар арасында варислары өч елдан соң мирас хокукы турында таныклык алмаган җирле салымнар буенча бурычлар.

2. Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән өстәмә нигезләр буенча пеня һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә һәм исәптән төшерүгә өметсезлекне юкка чыгару турында карар салым түләүченең урнашу урыны буенча салым органы тарафыннан кабул ителә.

3. Салым органының җирле салымнар буенча недоимканы түләттерүгә һәм исәптән төшерүгә өметсез дип тануы, түбәндәге раслаучы документлар булганда кабул ителә:

1) җирле салымнар буенча недоимкалар, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычлар, исәптән чыгарылырга тиешле сумма турында Салым түләүченең урнашу урыны буенча салым органы белешмәләре;

2) Гражданлык хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелә торган үлү турында белешмә яисә физик затны вафат булган дип игълан итү турында суд карары күчермәсе;

3) Үлгән көнгә недоимка, пеня һәм штрафлар, җир һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча бурычлары булган физик зат вафатыннан соң ачылган мирасны кабул итү турында гаризаларның булмавы хакында нотариус тарафыннан бирелгән белешмә;

4) "Башкарма производство турында" гы 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4 пунктында каралган нигезләр буенча башкарма җитештерүне тәмамлау турында суд пристав-башкаручысы карары күчермәләре.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренен рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге” башлыгы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге” Советы рәисе** **Ф.Г. Гарифуллин**